*Муниципаль тур*

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар теленнән олимпиада биремнәре**

***(2017/2018 нче уку елы)***

**IV сыйныф**

***Үткәрү вакыты – 90 минут***

***Максималь балл - 41***

**I. Бирелгән сүзләрнең синонимнарын уйлап языгыз.**

Ватан, кечкенә, эш, зур, чиста, матур, яхшы, өй, тиз, салмак

**II. Җөмләләрне укыгыз. Җәяләр эченнән тиешле сыйфатны сайлап күп нокталар урынына куегыз.**

1. Җәйнең иң ... (сылу, матур, зифа) көне булгандыр бу.

2. Урман артындагы ... (киң, тар, юка) кырларны үткәч, ... (тар, зур, калын) дәрьяны күреп алдылар.

3. Ак болыт, һәй, ак болыт,
Йөзәсең ... (салмак, әкрен, сүлпән) кына.

4. Таһир – ... (мактанчык, тыйнак, игътибарлы) малай, мактанырга, көчен, елгырлыгын күрсәтеп масаерга яратмый.

5. Алар, кояшның ... (кайнар, җылы, салкын) нурларына иркәләнеп, аллы-гөлле чәчәкләрдән ширбәт җыялар.

6. Үткән кыш әле бик ... (кечкенә, зур, юка) иде, хәзер инде шактый үскән бу малай, дип тә уйлады әле.

7. Ана каз бер нәрсәгә күз салмый, ... (нечкә, киң, тәбәнәк) муенын алга сузып, вак, җитез адымнар белән бәбкәләре янына ашыкты. *(Ф. Сафин)*

**III. Тестлардан берәр дөрес җавапны табыгыз.**

1. Бирелгән җөмләдә кече тел тартыгы булган сүзне күрсәтегез.

*Чикерткә, туктап, тирә-юньне күзәтте.*

а) чикерткә

ә) туктап

б) тирә-юньне

в) күзәтте

2. Бирелгән җөмләдә ике иҗекле сүзне билгеләгез.

*Чишмәнең суы ташларне камаштыра. (Г. Бәширов)*

а) чишмәнең

ә) суы

б) ташларне

в) камаштыра

3. Җөмләдә бирелгән исемнәрнең килешләрен күрсәтегез.

*Менә бүген дә әтисе, әнисе, кеп-кечкенә энесе Рөстәм белән әбиләренә кунакка кайтып төштеләр (Ф. Сафин)*

а) баш килеш, төшем килеше

ә) иялек килеше, юнәлеш килеше

б) чыгыш килеше, урын-вакыт килеше

в) баш килеш, юнәлеш килеше

4. Бирелгән җөмләдә алмашлыкны билгеләгез.

*Дөньяда әнисенең бишек җыры моңнарында тибрәнеп йоклаудан да рәхәт нәрсә бар микән?! (Н. Каштанов)*

а) дөньяда

ә) моңнарында

б) нәрсә

в) бар

5. Бирелгән җөмләдә аергыч булып килгән сүзләрне күрсәтегез.

*Кыз озын керфекләрен түбән төшерде, елап җибәрергә әзерләнеп, кечкенә иреннәрен бөрештереп куйды. (Ф. Сафин)*

а) керфекләрен, иреннәрен

ә) елап, бөрештереп

б) түбән, җибәрергә

в) озын, кечкенә

**IV. Сүзләрне татарчага тәрҗемә итеп, аларның антонимнарын шакмакларга языгыз.**

длиннее –

шире –

тяжелее –

больше –

**V. Туган тел турында 5 мәкаль уйлап языгыз.**